**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 1 февраль № 45

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина-санитария һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 11 ноябрь, 855 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина-санитария һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 11 ноябрь, 855 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Теркәлгән Мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын расларга.»;

әлеге карар белән расланган Медицина-санитария һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

әлеге Стандартның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты»;

1 бүлектә:

беренче абзацта «медицина-санитария һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме» сүзләрен «мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән беренчел медицина-санитария ярдәме» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары»;

уналтынчы абзацны төшереп калдырырга;

3 бүлектә:

1 пунктны түбәндәге  редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1. | Гражданның шәхесен таныклаучы документ: Россия Федерациясе гражданы паспорты | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары | гамәлдәге законнар нигезендә»; |
| | туу турында таныклык (14 яшькәчә балаларга) | граждан хәле актларын язу органнары | |

7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.4 һәм 7.5 пунктлар өстәргә:

«7.4. Учреждениеләрдә дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләренә (шул исәптән картларга, инвалидларга) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен законнар һәм бүтән норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә объектларның һәм хезмәтләрнең һәркемгә ачык булуын тәэмин итү юлы белән шартлар тудыралар (Учреждениеләргә каршылыксыз керү һәм чыгу, дәүләт хезмәтен күрсәтү урынында барып җитәр өчен Учреждение территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән Учреждение хезмәткәрләре ярдәме белән, мәгълүмат йөртү җайланмаларны тиешенчә урнаштыру, шул исәптән хезмәтне алу өчен кирәкле тавышлы һәм күрү өчен мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм бүтән текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокта шрифты белән башкарылган билгеләр  белән һәм контраст фонда кабатлау һ.б.ш.).

7.5. Дәүләт хезмәтенә сорау аны күрсәтү мөмкинлегеннән артып киткән очракта дәүләт хезмәтен күрсәтүне көтү вакытлары һәм чиратлылык Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган тиешле елга Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга  бушлай медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы белән билгеләнә.»;

11 бүлектә:

«Дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм һәркем алырлык булуы белән канәгать дәүләт хезмәтен алучылар өлеше» юлын төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Медицина ярдәме һәм медицина ярдәме стандартлары нигезендә күрсәтү тәртипләренә туры килү | процент | (Соб / Со) х 100%, монда: Соб – медицина ярдәме стандартлары бозмыйча хезмәт күрсәтү очраклары; Со – медицина ярдәме сыйфатын эчке, ведомство һәм ведомстводан тыш контрольдә тоту үткән хезмәт күрсәтү очраклары | мониторинг нәтиҗәләре | 80 | 8 |
| Кулланучыларның күрсәтелгән дәүләт хезмәте белән канәгать булуы | процент | (Оп + Оч) х100% / О, монда: Оп – сораштырылганнардан дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм һәркем алырлык булуы белән тулысынча канәгать булучылар саны; Оч – сораштырылганнардан дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм һәркем алырлык булуы белән өлешчә канәгать булучылар саны; О – сораштырылган гражданнарның гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре | 80 | 9»; |

12 бүлектә:

12.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) дәүләт хезмәтен күрсәтүче Учреждениегә язмача рәвештә кәгазьдә яисә электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Учреждение җитәкчеләре кабул иткән карарларга шикаятьләр дәүләт хезмәтен күрсәтүче Учреждениене гамәлгә куючыга җибәрелә.».

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт учреждениесе (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне), хроник бавыр эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ, хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга перитонеаль диализ оештыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында» 2011 ел, 29 декабрь, 1091 нче карарының 1 пунктындагы өченче абзац;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 7 июль, 457 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне диспетчерлаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 6 август, 573 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психикалары бозылудан интегүче авыруларга хезмәт терапиясе үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 13 август, 589 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 24 февраль, 108 нче карары.

3. Бу карарның көче 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\45.docx